МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.05.2016 г.Казань № 114/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2016 № 1/2-пр боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге “Үсемлекчелек өлкәсендә, шулай ук орлыклык бәрәңге һәм ачык грунттагы яшелчәләр җитештерүне үстерү өлкәсендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” № 1431 карарларын үтәү максатларында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2016 № 1/2-пр боерыгына (алга таба – Боерык) (16.02.2016 № 15/2-пр, 21.03.2016 № 45/2-пр боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 1.16 пунктчасы белән тулыландырырга:

“1.16. Шушы боерыкка карата кушымтага туры китереп, “2016 елда орлыклык бәрәңге һәм ачык грунттагы яшелчәләр җитештерүне үстерү өлкәсендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибе (16 кушымта).

2. Боерыкка карата 16 кушымтаны шушы Боерыкка карата кушымтага туры китереп, яңа эчтәлегендә бәян итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Премьер – министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының 15.01.2016 № 1/2-пр (ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының 27.05.2016 № 114/2-пр боерыгы төзәтмәсендә) боерыгына карата 16 кушымта

2016 елда орлыклык бәрәңге һәм ачык грунттагы яшелчәләр җитештерүне үстерү өлкәсендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип 2016 елда, милекчелек рәвешләре нинди булуга карамастан, Татарстан Республикасы территориясендә үсемчелек продукциясен җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси хуҗалык тотучы гражданнардан тыш) орлыклык бәрәңге һәм ачык грунттагы яшелчәләр җитештерүне арттыруны тәэмин итүче агротехнологик эшләр комплексын үткәрүгә чәчүлек мәйданының 1 гектарына исәпләнгән күләмдә чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен билгели (алга таба - субсидияләр, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре, субсидияләрне алучылар).

2. Субсидияләрне бирүнең максаты булып авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең орлыклык бәрәңге һәм ачык грунттагы яшелчәләр җитештергәндә чыгымнарының бер өлешен каплау тора.

3. Субсидияләрне алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлаап алу критерийлары булып орлыклык бәрәңге һәм ачык грунттагы яшелчәләр җитештерү һәм сату тора.

4. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрендә милекчелектә һәм (яки) аренда шартларында орлыклык бәрәңгене һәм ачык грунттагы яшелчәләрне чәчү кишәрлекләренең булуы 2016 елда субсидияләрне бирү шартлары булып тора.

5. Орлыклык бәрәңге һәм (яки) ачык грунттагы яшелчә культураларының җимешлекләре һәм орлыклыклары белән утыртылган чәчүлек кишәрлекләренә ия булган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган ставкалар нигезендә, 2015 ел өчен чәчү йомгаклары турында рәсми статистика хисабыннан формалаштырылган мәгълүматка (алга таба – 2015 ел өчен чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат) карап, 1 гектарга бирелә.

6. Ачык грунттагы яшелчә культураларын чәчү өчен чәчүлек кишәрлекләре булган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган ставкалар нигезендә 2015 ел очен чәчүлек мәйданнары турында мәгълүматка карап, 1 гектар өчен бирелә.

7. Арбитраж суды тарафыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган очракта,

алар (авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бу хакта Министрлыкка эш кузгатылган көнне язмача хәбәр итәргә тиеш.

8. Шушы Тәртипнең 5 пунктына туры китереп, субсидия алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза;

2015 ел өчен чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат

авыл хуҗалыгы культураларының орлыкларын җиткерү шартнамәсе;

орлыклар өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәсе;

орлыклар сатып алуга товар-транспорт накладное;

орлыкларның сыйфат ярашлылыгы турында сертификат;

карантин сертификаты һәм фитосанитария контрольлеге турында акт (орлыкларны Татарстан Республикасы чикләреннән керткәндә);

2015 елда чәчүнең сорт сыйфатларын апробацияләү акты;

милектә һәм (яки) аренда шартларында авыл хуҗалыгы культураларын чәчү кишәрлекләре булуны раслый торган документлар;

Министрлык раслый торган рәвештә тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә.

9. Шушы Тәртипнең 6 пунктына туры китереп, субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза;

2015 ел өчен ачык грунттагы яшелчә культураларының чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат;

Министрлык раслый торган рәвештә тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә.

10. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Идарәгә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы билгели торган рәвешләрдә һәм Министрлык билгели торган срокларда финанс-икътисади торыш турында хисапнамә тапшыралар.

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре финанс-икътисади торыш турында хисапнамәне үз вакытында тапшырмаган очракта, Министрлык закон нигезендә дәүләт ярдәме чараларын күрсәтүне туктата.

11. Идарәләр:

а) субсидияләр бирү турында гаризаларны кергән көнендә журналда теркиләр, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш;

б) шушы Тәртинең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерәләр. Документларны карап тикшерү вакыты гаризаны теркәгән көннән башлап 15 эш көне тәшкил итә;

в) аталган документлар нигезендә Министрлык раслаган рәвештә Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча тиешле субсидияләр турында җыелма белешмә-исәпләмәләр төзиләр һәм 2 эш көне чорында Министрлыкка тапшыралар.

12. Субсидияләр гаризаларны тапшыру тәртибендә бюджет акчаларының лимит кысаларында бирелә

Субсидияләрне бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларны тулы күләмдә тапшырмау яки аларның шушы Тәртип таләпләренә җавап бирмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитында калдык өлеш булмау.

Субсидияләрне бирүдән баш тарту очрагында, Министрлык 11 пунктта күрсәтелгән вакыт узганнан соң эш көннәрендә хисаплана торган 5 көнлек чорда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә баш тарту турында белдерүнамә җибәрә.

Субсидияләрне бирүдән баш тарту законда билгеләнгән тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.

13. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль идарәләрендәге лицевой счетларга, акча чараларын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне эчендә, акча чараларын күчерүне хәл итә.

Министрлык, Министрлык тарафыннан расланылган форма буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларныц субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

Субсидияләр күчерүгә нигез булып Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмәләр тора. Идарәләр бюджет акчаларын алган көннән соң 5 эш көне дәвамында субсидияләрне авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең исәп-хисап счетларына күчерәләр.

14. Максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемenә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары

субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемена кире кайтарылырга тиеш.

16. Бу Тәртипнең 14 һәм 15 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын федераль бюджет керемена ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

17. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

18. Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Идарәгә тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.